РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛАНДЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Гагарина ул., д. 4, с. Баландыш, 422098
тел. (факс): (84360) 55-6-10,
E-mail: Bln.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНДЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Гагарин ур., 4 нче йорт, Баландыш авылы, 422098
тел. (факс): (84360) 55-6-10
E-mail: Bln.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053609 ОГРН 1061675010154 ИНН/КПП 1619004362/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 4**

**КАРАР**
**09.03.2022ел**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы ЛХ-28/418/2022 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегендә 6964,98сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче Р.Ш.Мөхәммәтшин

Теләче муниципаль районы
Баландыш авыл җирлеге Башкарма
комитетының 09.03.2022 ел №4
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2022 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 135,50 |
| 2.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2900,14 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 828,72 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3100,32 |
| Барлыгы | 6964,98 |